# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2025 елның 01 ноябрендәге** **2 номерлы**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм бер тапкыр түләнә торган 2 төркем инвалидлар өчен 500 сум күләмендә түләү.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- урамнарны яктырту җайланмасы (Катимовская урамында);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (м. Сәхбиев ур. юлын чокырларга ремонтлау һәм профильләштерү);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материал, җайланмалар сатып алу, тишелешләрне бетерү, торбаларны алмаштыру);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чаптыру, триммер һәм трактор чапкычы өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту):

3.Әлеге карарны Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче, Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы

И. М. Мөхәммәтҗанов